Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының
Исләй авыл җирлеге башлыгы
Карары

2020 елның 30 октябре №_4_

«Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Чистай муниципаль районы Исләй авыл җирлегенең Исләй авылында гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Чистай муниципаль районының «Исләй авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең 22 статьясы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. 2020 елның 20 ноябрендә 14.00 сәгатькә авыл клубы бинасында Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Исләй авыл җирлегенең Исләй авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Татарстан Республикасы, Чистай районы, Исләй авылы, 8 март ур., 19б йорт.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«2021 елда Чистай муниципаль районы Исләй авыл җирлегенең Исләй авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән үзара салым кертүгә, балачактан инвалидлардан, 1 төркем инвалидлардан тыш, 500 сум күләмендә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән ризалашасызмы:

- Исләй авылында авыл эчендәге юлларны ремонтлау һәм карап тоту (вак таш сатып алу һәм китерү, грунт салу һәм грейдирование, вак таш салу, юлларны тигезләү, кар чистарту, чокырларны каплау, килешүләр буенча түләү).

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Җыенны оештыручы итеп Чистай муниципаль районының Исләй авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

4. Әлеге карарны авыл җирлегендә яшәүчеләрне күпләп җыелган урыннарда, игълан итү стендларында һәм такталарында элү юлы белән игълан итәргә, шулай ук Чистай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Чистай муниципаль районының
Исләй
авыл җирлеге башлыгы В.П.Чернышев